**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘМБАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2018 елның 29 гыйнвары № 104

**Шәмбалыкчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2017елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. 2016 елның 15 апрелендәге 25 номерлы карар белән расланган Шәмбалыкчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.7. Җирле үзидарә органыны яисә вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгать "Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законында күрсәтелгән тәртип буенча каралырга тиеш.

Мөрәҗәгатьтә гражданин үзенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булса), җавап җибәрелү өчен электрон почта адресын, мөрәҗәгатьне кире кайтару буенча хәбәрнамәне күрсәтә. Гражданин шундый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада куярга хокуклы.";

2) 3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.8. Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат тарафыннан мөрәҗәгать каралганда гражданин түбәндәге хокукларга ия:

өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга яки аларны сорату турында, шул исәптән электрон формада, мөрәҗәгать итәргә;

башка затларның законлы мәнфәгатьләренә, ирек һәм хокукларына кагылмаган һәм әлеге документларда, материалларда дәүләт серләре һәм федераль закон тарафыннан саклана торган башка серләр булмаган очракта мөрәҗәгатьне карарга юнәлтелгән документ һәм материаллар белән танышырга;

“Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законының 11 статьясында күрсәтелгән искәрмә очраклары булмаса, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларга язмача җавап алырга, ә әлеге Федераль законның 11 статьясындагы 5.1 өлешендәге очракта мөрәҗәгать нигезендә язмача мөрәҗәгатьне тиешле җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җибәрү турындагы хәбәрнамәне алырга;

мөрәҗәгатьне административ һәм (яки) суд тәртибендә Россия Федерациясе законнары нигезендә карау белән бәйле булганда мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карар яки гамәл буенча шикаять язарга;

мөрәҗәгатьне карауны туктатырга дип гариза язарга.”;

3) 4. 15 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.15.Электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органнарына яки вазыйфаи затка булган мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәрелә, язмача мөрәҗәгатькә - мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язмача җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка кергән билгесез даирә затлары мәнфәгатьләренә кагыла торган тәкъдимнән, гаризадан яисә шикаятьтән гыйбарәт мөрәҗәгатькә, аерым алганда билгесез даирә затларына каратачыгарылган суд карарына шикаять бедерелгән җавап, шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибе аңлатылган җавап “Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендгы 59-ФЗ номерлы Федераль законынның 6 статьясының 2 өлешендәге таләпләрен үтәп, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Апас муниципаль районы официаль сайтының Шәмбалыкчы авыл җирлеге бүлегенә урнаштырылырга мөмкин.”

4) 4.16 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

5) түбәндәге эчтәлекле 5.1.1 пункт өстәргә:

«5.1.1.Язмача мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гариза яки шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен тиешле компетенциясе булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде кән эчендә хәбәр ителә.”;

6) түбәндәге эчтәлекле 5.1.2 пунктны өстәргә:

«5.1.2.Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җавабы “Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законыны 10 статьясының 4 нче өлешенә туры китереп "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Апас муниципаль районы официаль сайтының Шәмбалыкчы авыл җирлеге бүлегендә урнаштырылган мәсьәлә буенча язмача мөрәҗәгать кергән очракта, аны теркәгән көннән алып җиде көн эчендә элеге мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләгә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, бу чакта суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать кире кайтарылмый.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар официаль порталында бастырырга һәм Апас муниципаль районы официаль сайтының Шәмбалыкчы авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар официаль бастырган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Шәмбалыкчы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **/Ф.Ф.Миннуллин /**